# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Административ хокук бозулар турында**
**Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 15 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2011, 22 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.11 статья өстәргә:

"2.11 статья. **Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турындагы Татарстан Республикасы законнарын бозу**

Күпфатирлы йортларга идарә итү, күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең уртак мөлкәтен карап тоту, коммуналь хезмәтләр күрсәтү, торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүдән алына торган чыгымнарны тоту өлкәсендә гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турындагы Татарстан Республикасы законнары таләпләрен үтәмәгән өчен –

вазыйфаи затларга – дүрт меңнән алып биш мең сумга кадәр; юридик затларга кырык меңнән алып илле мең сумга кадәр административ штраф салына.";

2) 7.1 статьяга "2.9" саныннан соң "2.11," санын өстәргә;

3) 8.1 статьяга түбәндәге эчтәлекле яңа унынчы өлеш өстәргә:

"Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган очраклардан тыш, әлеге Кодексның 2.11 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрне Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең вазыйфаи затлары төзергә хокуклы.";

4) унынчы һәм унберенче өлешләрне тәңгәл рәвештә унберенче һәм уникенче өлешләр дип санарга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011елның 10 октябре
№ 70-ТРЗ